КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 7 сентябрь г.Казань № 793

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2013 ел, 31 июль, 538 нче карары белән расланган Фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2013 ел, 31 июль, 538 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 17 март, 159 нчы; 2016 ел, 30 декабрь, 1056 нчы; 2017 ел, 18 сентябрь, 696 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә, аңа түбәндәге эчтәлекле 6.11 нче пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«6.11. Учреждениенең гамәлгә куючысы тарафыннан фәнни оешманың фәнни җитәкчесе вазыйфасы гамәлгә кертелгәндә фәнни оешмадагы фәнни җитәкчесенең эш хакы бу Нигезләмәнең 6.4, 6.6 – 6.10 нчы пунктлары нигезендә учреждение җитәкчесе урынбасары дәрәҗәсендә билгеләнә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин